2023
ГОД НАЦИОНАЛЬНЫХ
КУЛЬТУР И ТРАДИЦИЙ
милли мәдәниятләр
һәм гореф-гадәтләр елы

**Изге мирасыбызны саклыйк!**

Варислардан варисларга күчсен,
Гасырлардан күчсен гасырга.
Изге мирас-туган җирне, телне
Без сакларга тиеш, сакларга.
Асия Маликова.

Татар халкының гасырлар буена тупланып килгән мирасын, күңел бизәкләренең матурлыгын балаларга җиткерү, аларның күңелендә милли мәдәняткә мәхәббәт тәрбияләү-укытучыларның изге эше ул.Халкыбызның сәнгатен, көнкүрешен өйрәнгәндә, балаларда туган җиргә мәхәббәт, үткәннәргә хөрмәт хисләре уяна, буыннар арасында элемтә, бәйләнеш туа. Безнең мәктәптә Капитолина Андреевна Сидоркина исемендәге “Туган якны өйрәнү” музее эшләп килә. Музейда экспонатлар шактый күп. Аларда ата-бабаларыбызның күңел җылысы, рухы, изге хатирәләре саклана. Сыйныфтан тыш чара вакытында, 5нче сыйныф укучылары,  “Татар өе” дигән бүлек белән таныштылар. Килеп кергәч тә, үзеңне музейда түгел, кунакчыл татар өендә кебек хис итәсең. Андагы әйберләр турында сөйләгәндә, аларның күңелләрендә кызыксыну уянды, экспонатларны тотып –тотып карадылар. Димәк, без, укучылар белән берлектә, изге мирасыбызны сакларбыз дигән уйда калам.

